**УРАМНАРЫБЫЗ АЛАР ИСЕМЕН ЙӨРТӘ**

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ



Бөек татар шагыйре, фикер иясе һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукай (1886 - 1913) Татарстан Республикасының Арча районы Кушлавыч авылында туган. 4 яшендә ятим калып, аңа тормышның әчесен дә, татлысын да бик иртә татырга туры килә. Уральск шәһәренә күчеп, мәдрәсәдә укый һәм шунда ук рус классында белем ала.

Шигырьләрен 1902 елда яза башлый, типографиядә җыючы булып эшли, «Фикер» («Мысль») газетасында, «Әл - гасыр - әл - җәдит» («Новый век») журналларында хезмәттәшлек итә, шунда ук шигырьләрен, публицистик мәкаләләрен, фельетоннарын бастыра.

1907 елда Казанга килгәч язучы - демократлар белән якынлаша. Г.Камал белән берлектә «Яшен» («Молния») сатирик журналын нәшер итә. «Ялт - йолт» («Зарница») журналында эшли. Шигырьләре һәм памфлетларында монархистларны һәм буржуаз милләтчеләрне фаш итә. Тукайның иҗатында революцион заманчалык, халык массаларының азатлык өчен көрәше төп билгеләүче башлангыч булып тора. Шигырьләрендә фәкыйрьләрнең, изелгән татар хатынының авыр тормышы турында ачынып сөйли. Ә туган ягына мәхәббәт, хезмәт халкының шигъри аваз иҗатына хөрмәт хисләре «Шүрәле» әкият - поэмасында ачык чагыла.

Тукай татар тәнкыйди реализмына нигез салучы шагыйрь. Татар халкының бөек җырчысы, татар әдәбиятында демократик һәм революцион юнәлешкә нигез салучы. Аның байрагы халыкка хезмәт итү һәм аны изүдән азат итү идеаллары белән җилфердәде.

Тукай - милли әдәби - шигъри тел тудыручы шагыйрь. Ул Пушкин, Лермонтов, Майков һәм башкаларны татар теленә тәрҗемә итә.

Бүген үзенең шигырьләре дә бик күп халык теленә тәрҗемә ителде. Тукай иҗаты үзенең әһәмияте ягыннан XX гасыр дөнья культурасына үз өлешен кертте. Нәкъ шуңа күрә бөек татар улы Габдулла Тукайның йөзьеллыгы Юнеско тарафыннан дөньяви масштабтагы вакыйга буларак билгеләп үтелде.

**Рубриканы И.Сандлер алып бара.**

## Хуш, бөек Артист!

Бүген Юрий Владимирович Никулин белән хушлашуның соңгы көне. Мәскәү генә түгел, бөтен Россия зур кайгыда. Әле күптән түгел генә аның 75 еллык юбилеен бәйрәм иткәннәр иде һәм телевидение ярдәмендә без дә ул зур тантананың шаһитлары булдык. Ул чакта бөек артистның олы яше турында авыз ачучы да булмады - ул көнне дә соңгы еллардагы «Ак попугай» клубындагы ачык күңелле, бераз гына кинаяле һәм зирәк иде ул. Бернинди купшылыксыз һәм эчкерсез үткән иде ул кичә. Юрий Владимировичның хатыны Татьяна Николаевна белән тәхеттә утыруы да бик табигый иде, чөнки тамашачы тарафыннан аның Артист, Шәхес, Игелек иясе буларак гәүдәләнеше кебек кабул ителде.

Кинотәнкыйтьчеләр «Бриллиантлы кул»га кадәр Никулин төп рольләрдә уйнамады дип раслый килделәр. Юк, дөрес түгел бу. Аның «Пес Барбос һәм гадәти булмаган Кросс», «Самагончылар», «Ы» операциясе һәм «Шурикның башка маҗаралары» дигән һәм башка фильмнарындагы эшләре генә дә аның йөзләрчә коллегаларының хезмәтенә караганда күпкә истә калырлыграк иде. Никулин һәрвакытта да экранда һәркемгә аңлаешлы һәм истә калырдай образлар иҗат итте. Еллар үтү белән аны үз образлары белән бер итеп кабул итә башладык без. Шулкадәр дә гади - хәйләкәрлекне ябыштырып та булмый аңа.

Монда, үзәктән читтә, без Юрий Никулинны клоун буларак азрак беләбез. Әмма аның иҗат юлын нәкъ шул рольдә, еш кына Михаил Шуйдин белән бергә чыгышлардан башлаганлыгын яхшы хәтерлибез. Соңрак ул Цветной бульвардагы циркның директоры булды.

Бүген без Никулин белән, Бөек Клоун, Үз Артистыбыз белән хушлашабыз.

**РЕДКОЛЛЕГИЯ.**

## Бу кызыклы

### *Америка туе - иң зур килешү ул*

АКШта гаилә кору, биредә яшәүче урта хәлле кешенең ярты еллык хезмәт хакын - 16 мең доллар тәшкил итә. Анда 500 - 800 долларлык кияү смокингы, кәләшнең 800 долларлык туфлие һәм башка кирәк - ярагы кирә. Ә туй күлмәген бер кию 1 - 7 мең доллар тора, фотограф, видеотасмага төшерү 500 - 1,5 мең доллар бәяләнә. Яшьләрне банкет урынына илтеп кую 100 долларга.

Туйның иң җаваплы өлеше - банкет. Махсус туйга алынган залдагы һәр кешене сыйлау (ул кимендә 50 була) 70 долларга төшә.

Бүләк алу күңелле күренешләрнең берсе. Кунаклар аны алдан яшьләр яшисе йортка илтеп куялар. Америкада гадәттә йорт кирәк - яраклары, техник җиһазлар, урын - җир әйберләре бүләк итәләр.

## Белдерүләр



### Сатабыз

Ике бүлмәле фатир. Тел.: Самарада 33 - 29 - 67.

***

1982 елда чыккан «Москвич - 2140», әйбәт хәлдә. Адрес: Козлов ур., 4 - 12.

***

ВАЗ - 2106 автомашинасы. Адрес: 50 лет Победы урамы, 2 - 6.

***

«Москвич - 412» «крыло»лары, алгы балка. Тел.: 2 - 21 - 98 (кичке сәг. 8дән 11гә кадәр).

***

Красин урамында 10 нчы йорт. Теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә.

***

Яңа газ колонкасы. Тел.: 5 - 38 - 37 (кичке 7дән соң).

***

40 ат көчле «Запорожец». Тел.: 5 - 18 - 42.

***

«Муравей» мотороллеры, кыйммәт түгел, әйбәт хәлдә. Югары Норлат авылында Мөхәммәдъяров Шәрифуллага мөрәҗәгать итәргә.

***

Ашыгыч рәвештә тимербетон гараж. Кооператив ур., 4 - 19. Тел.: 2 - 12 - 18.

***

НГДУ ЖКХсы янында коры базы белән капиталь гараж, куллануда булган йомшак җиһаз. Космонавтлар ур., 31а - 2.

***

Йөкташучы һәм 5 урынлы ПАЗ, кыйммәт түгел, 1996 елда чыккан җиңел автотаккыч, 7 урынлы яңа «Газель». Самара өлкәсе, Кошки авылы, Луговая ур., 100. Тел.: (код 250) 2 - 23 - 80.

***

1995 елда чыккан дизельле, бортлы, тентлы «ГАЗ - 3309» (ГАЗ - 53) машинасы. Тел.: 2 - 10 - 94, 2 - 19 - 19.

***

Заводта эшләнгән җыелма гараж («әкәм - төкәм» тибында). Тел.: 5 - 15 - 30 (кичке 4тән соң).

***

Барлык уңайлыклары белән беренче катта аерым керү юлы булган ике бүлмәле фатир. Кладовкасы, базы, участогы бар. Тел.: 2 - 16 - 28.

***

Фундамент блоклары, 6 x 1,5 плитәләре, кызыл кирпеч һәм газобетон. Тел.: 65 - 8 - 88.

***

Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир. Тел.: 5 - 29 - 57.

### Алмаштырабыз

Ульяновск шәһәрендәге (Яңа шәһәр) ике бүлмәле фатир Норлаттагы шундый ук фатирга алмаштырыла яки сатыла. Тел.: 3 - 31 - 01.

***

Школьная урамындагы йорт төзелеше өчен участок бер бүлмәле фатирга өстәмә түләп алмаштырыла яки сатыла. Тел.: 65 - 8 - 88.

### Эшкә чакырабыз

«Норлат» ресторанына официанткалар таләп ителә.

### Төрлесеннән

Гаилә җиһазланмаган фатир эзли. Тел.: 2 - 16 - 19, кичке сәг.4тән 7гә кадәр.

***

Яшь гаилә фатир эзли (шикәрчеләр поселогында булуы әйбәтрәк). Завод ур., 10 - 7. Тел.: 2 - 13 - 89.

***

«Мелиорация» Октябрь ПМКсы АҖ, 1997 елның 12 сентябрендә, сәг. 8дә акционерларның гомуми җыелышы үткәрелүе турында хәбәр итә. Адрес: Норлат шәһәре, Гыймалетдинов ур, 162. Акционерларның шул ук көнне сәг. 7дә паспортлары белән килүләре сорала.

***

Гыйльманов Илгиз Зәкиевич исеменә бирелгән шофер таныклыгы, техпаспорт табучының бүләк бәрабәренә Козлов урамы, 14 - 2 адресы буенча китерүегезне үтенәбез.

## Кунакханә

**Без һәрвакыт ашыгабыз, кабаланабыз, йөгерәбез. Бер - беребезне күрергә, хәл - әхвәлләрен сорашырга, сөйләшеп утырырга да вакытыбыз юк. Хәтта бу гаиләдә дә шулай. Ичмасам кичке аш, ял көнге көндезге аш вакытларында гына булса да, бергә булып, чын - чынлап бәйрәм табыны ясарга иде.**

**Моның өчен шушы уңай белән махсус әзерләнгән салат, камыр ризыгы, торт бик кулай. Бүген сезгә аларның берничәсен тәкъдим итәбез.**

### Чөгендерле тозлаган кәбестә

Башта маринад ясыйбыз. 1 литр суга ярты стакан көнбагыш мае, 1 стакан (тулар - тулмас) шикәр комы, 2 аш кашыгы тоз, 1 стакан (шулай ук тулар - тулмас) серкә салып кайнатабыз.

Кәбестәне, күчәнен кертмичә, эре итеп (4 см. x 6 см.) турыйбыз. Эре угычта кишер, кызыл чөгендер уабыз. 5 - 8 тырнак сарымсак чистартабыз. 3 литрлы чиста банкага кәбестәне, кишер, чөгендер, сарымсакны араластырып тутырабыз да өстенә яңа кайнап чыккан маринадны салабыз. Суынгач, суыткычка куябыз. Бер тәүлектән кәбестә әзер.

### Пицца

Берничә кишерне эре угычта уып, суганны салам шикелле турап бергә кушарга да табада үсемлек мае кыздырып, шуның өстенә салырга. Берникадәр вакыт болгата - болгата кыздыргач, өстенә томат соусы һәм чәй кашыгы очына элеп бераз аджика өстәргә. 2 - 3 пешкән йомырканы, колбаса яки пешкән итне турап өстенә салырга.

Чүпрәле камырны табага җәеп, өстенә шушы эчлекне салып, аның өстенә зур угычтан уылган сыр, помидор булса, телемләп помидор турап бизәргә дә, майонез белән сылап чыгарга кирәк. Духовкада камыры кызарганчы пешереп алырга.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2334 данә.